РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ**

**КАРАР**

«28» ноябрь 2025г. г. Альметьевск №14

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмә хакында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Кадрлар үзгәрешләренә бәйле рәвештә

Әлмәт муниципаль районы Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2018 елның 15 ноябрендәге 253 номерлы «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу комиссиясе турындагы нигезләмә хакында»гы карарына» (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2020 елның 12 мартындагы 367 номерлы, 2020 елның 30 октябрендәге 12 номерлы, 2021 елның 11 мартындагы 36 номерлы, 2021 елның 16 декабрендәге 114 номерлы, 2022 елның 20 апрелендәге 143 номерлы, 2023 елның 06 декабрендәге 266 номерлы, 2024 елның 13 ноябрендәге 322 номерлы, 2025 елның 7 мартындагы 343 номерлы үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарага 2 нче кушымта «Хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга карата таләпләрне үтәү комиссиясе составы»:

а) комиссия составыннан А.И. Грушинны чыгарырга;

б) комиссия составына Әлмәт муниципаль районы Советы депутаты (килешү буенча), «Светсервис» муниципаль унитар предприятиясе директоры Сөләйманов Җәүдәт Әхнәф улын кертергә.

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә (Туманова Г.П.) йөкләргә.

Муниципаль район Башлыгы Г.М. Хәбутдинова